**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Федотовка авыл җирлеге Федотовка торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

2023 елның 31 гыйнвары №1

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлегенең «2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында» 2022 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы карарына өстәмә кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлеге Федотовка торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлегенең «2023 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Федотовка авыл җирлегенең Федотовка торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2022 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы карарында түбәндәге өстәмәне кертергә:

2 пунктта түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә, җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

Федотовка авылы Советская урамында каптажны һәм өлешчә су белән тәэмин итү линиясен ремонтлау».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Федотовка авылы, Совет урамы, 6 йорт, Совет урамы, 8 йорт (мәдәният йорты бинасы), Кузьминовка авылы, Кооперативная урамы, 10 йорт (авыл клубы бинасы), Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) “Авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен әлеге карарны җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районы
Федотовка авыл җирлеге башлыгы В.И.Павлова